Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXVI-1**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 19 ноябре

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары проекты хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 маддәләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 17, 88, 89, 90 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карар проектын беренче кушымтага ярашлы рәвештә беренче укылышта кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Расларга:

2 нче кушымта нигезендә “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен;

3 нче кушымта нигезендә “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибен.

.3. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитетын түбәндәге составта төзергә:

Ибраһимов Илнур Галим улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы урынбасары, оештыру комитеты рәисе;

Җамалиев Рөстәм Рәсим улы – Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы, оештыру комитеты әгъзасы;

Әхмәтвәлиева Резеда Габделәхәт кызы – Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының оештыру бүлеге башлыгы урынбасары, оештыру комитеты әгъзасы.

4. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны 2018 елның 2 декабренә 11 сәгатькә тъбщндщге адрес буенча билгеләргә: ТР, Балык Бистәсе штп., Ленин ур., 48 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының утырышлар залы.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары проектын, гавами тыңлауларда әйтелгән тәкъдимнәрне һәм аның буенча фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм карар проектын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советына икенче укылышта карауга кертергә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2018 елның 19 ноябрендәге
XXXVI-1 номерлы карарына
кушымта №1

**“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары проекты**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 маддәләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 17, 88, 89, 90 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 15.07.2016 ел №XI-1, 24.07.2017 ел №XX-1, 12.04.2018 ел № XXX-1 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кушымтага ярашлы рәвештә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алынганнан соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсендәге 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 90 маддәсендәге 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
20___ елның ___ _________
_____ номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 6 маддәнең 1 өлешендәге 17 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә: “,районны территориаль планлаштыру схемасын раслау, территорияне планлаштыру буенча районның территориаль планлаштыру схемасы нигезендә әзерләнгән документларны раслау, район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып бару, муниципаль ихтыяҗлар өчен район чикләрендә җир кишәрлекләрен резервлау һәм алу, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырылган параметрларының билгеләнгән параметрларына һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруга рөхсәтнамә бирелүе турында хәбәрнамә җибәрү, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырылган параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамәләр юллау, тиешле авылара территорияләрдә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамәләр җибәрү, авылара территориядә урнашкан рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турында Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә карар, авылара территориядә урнашкан бинаны сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карарлар, максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган һәм авылара территориядә урнашкан җир кишәрлеген кире алу турында карар кабул итү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда үз белдеге белән (рөхсәтсез) төзелгән корылманы сүтүне яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру, авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү”;

2) 7 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә: “Кулланучылар хокукларын яклау турында” 07.02.1992 ел, № 2300-1 Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру”;

3) 8 маддәнең 1 өлешендәге 13 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә: “,авыл

җирлекләренең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү, төзелешкә рөхсәтнамәләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан гайре), авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә бирү, авыл җирлекләрен шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау, җирләрне резервлау һәм авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен алу, авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карау һәм мондый тикшерүләр барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында рекомендацияләр бирү, индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкин булуы турында хәбәрнамә юллау (алга таба – планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә),
индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкин булмавы турында хәбәрнамә юллау, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының туры килү-килмәве турында хәбәрнамә юллау, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген кире алу турында карар кабул итү”;

4) 27 маддәнең 7 өлешендәге 1 пунктындагы түбәндәге сүзләрне “федераль законнарда каралган очракларны һәм оешма белән идарә итүдә катнашу Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән гамәлгә ашырыла торган очракларны” түбәндәге сүзләргә алмаштырырга: “Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәрнамә җибәреп коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан гайре);”;

5) 39 маддәнең 4 өлешендәге 1 пунктындагы түбәндәге сүзләрне “федераль законнарда каралган очракларны һәм оешма белән идарә итүдә катнашу Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән гамәлгә ашырыла торган очракларны” түбәндәге сүзләргә алмаштырырга: “Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәрнамә җибәреп коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан гайре);”;

6) 42 маддәнең 8 өлешендәге 1 пунктындагы түбәндәге сүзләрне “федераль законнарда каралган очракларны һәм оешма белән идарә итүдә катнашу Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән гамәлгә ашырыла торган очракларны” түбәндәге сүзләргә алмаштырырга: “Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәрнамә җибәреп коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан гайре);”;

7) 46 маддәдә:

а) 1 өлешнең 3 пунктындагы өченче абзацына түбәндәге сүзләр өстәргә: ”район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмати системаларын алып баруны, муниципаль ихтыяҗлар өчен муниципаль район чикләрендә җир кишәрлекләрен алуны, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырылган параметрларының хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның билгеләнгән параметрларына туры килүе һәм аларны әлеге җир кишәрлегендә урнаштыруның мөмкинлеге турында һәм параметрларның туры килмәве һәм урнаштыруның мөмкин булмавы хакында хәбәрнамә җибәрүне, индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты төзелгән яисә реконструкцияләнгән объектның тиешле авылара территорияләрдә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яисә бакча йортларын төзегәндә яисә реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә юллауны гамәлгә ашыра, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә, авылара территориядә урнашкан рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү яки аны билгеләнгән

таләпләргә туры китерү турында, максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган һәм авылара территориядә урнашкан җир кишәрлеген алу турында карар кабул итә, авылара территориядә урнашкан үз белдегең белән торгызылган корылманы сүтүне яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыра, авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирә;”;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

“13) “Кулланучылар хокукларын яклау турында” 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра.”;

в) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 15.1 пунктны өстәргә: “15.1) ”район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмати системаларын алып баруны, муниципаль ихтыяҗлар өчен муниципаль район чикләрендә җир кишәрлекләрен алуны, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырылган параметрларының хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның билгеләнгән параметрларына туры килүе һәм аларны әлеге җир кишәрлегендә урнаштыруның мөмкинлеге турында һәм параметрларның туры килмәве һәм урнаштыруның мөмкин булмавы хакында хәбәрнамә җибәрүне, индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты төзелгән яисә реконструкцияләнгән объектның тиешле авылара территорияләрдә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яисә бакча йортларын төзегәндә яисә реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә юллауны гамәлгә ашыра, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә, авылара территориядә урнашкан рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында, максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган һәм авылара территориядә урнашкан җир кишәрлеген алу турында карар кабул итә, авылара территориядә урнашкан үз белдегең белән торгызылган корылманы сүтүне яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыра, авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирә;”;

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2018 елның 19 ноябрендәге
XXXVI-1 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу Тәртибе**

**1.** Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре язма рәвештә үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советына кертелә:

| № п/п | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А.и., адрес, телефон, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча юллана: 422650, ТР, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт, каб. 4; почта аркылы: 422650, ТР, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт яисә (88-43-61)2-30-12 факсы буенча.

Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" карар проекты рәсми рәвештә игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көннән башлап эш көннәрендә сәг. 8 дән 17 сәгатьләрдә 2018 елның 30 ноябренә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422650, ТР, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт, каб. 4; почта аркылы: 422650, ТР, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт яисә (88-43-61)2-30-12 факсы буенча.

Заявкалар эш көннәрендә сәг. 8 дән 17 сәгатьләрдә ачык (гавами) тыңлаулар датасына чаклы 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителәләр.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә тапшырыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2018 елның 19 ноябрендәге
XXXVI-1 номерлы карарына
кушымта №3

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты буенча ачык (гавами) тыңлаулар уздыру Тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты буенча ачык (гавами) тыңлаулар (алга таба – тиңдәшле рәвештә ачык (гавами) тыңлаулар, карар проекты) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 17 маддәсе, Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә ачык (гавами) тыңлауларны (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 8 маддәсе нигезендә үткәрелә, ул Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-2 номерлы карары белән расланган.

2. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашучылар – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар тапшырган районда көн итүчеләр.

3. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукына ия булмый гына катнашучылар булып җирлекнең һәммә кызыксынучы кешесе торырга мөмкин.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 30 минут алдан башлана.

5. Ачык тыңлауларда район Башлыгы урынбасары – карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитеты рәисе рәислек итә.

6. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән башлана, ул залда булучыларга тикшерелә торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе хакында мәгълүмат ирештерә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, киңәшләрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында секретариат сайлана.

8. Төп доклад белән оештыру комитеты рәисе чыгыш ясый.

9. Ачык тыңлауларның чыгыш ясау хокукына ия катнашучылары гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чират тәртибендә үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырылалар.

10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга чыгыш тәмамланганнан соң рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыгылырга, аларны өзәргә һәм алып баруга комачауларга хаклы түгел.

13. Ачык тыңлауларны үткәргәндә тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибен бозу очрагында рәислек итүче аларны утырышлар залыннан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хаклы.

15. Чыгышлар төгәлләнгәннән соң рәислек итүче ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәр, киңәшләрне аныклау өчен ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык замечание һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә бирелә һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә. Ачык тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы материалларында саклана.

17. Ачык тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) халыкка игълан ителергә тиешле.

19.Ачык тыңлауларны үткәрүнең оештыру һәм матди-техник тәэмин ителеше Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов